РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының_____________
№ _____ боерыгы нигезендә

Министр

__________________Л.Р. Сафин

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ
Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының____________
№ _______ күрсәтмәсе нигезендә

Министрның беренче урынбасары

__________________ А.И. Галиев

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ КАРШЫНДАГЫ ТАТАРСТАННЫҢ ЮЛ-ТРАНСПОРТ КОМПЛЕКСЫН КАРАП ТОТУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА БАШ ИДАРӘСЕ» ДӘҮЛӘТ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
**УСТАВЫ**

Казан ш.
2018

# 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән оештырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре исемлеген раслау турында» 2010 ел, 17 август, 660 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт учреждениесенең дәүләт учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән оештырылды.

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт учреждениесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе турында» 2001 ел, 07 сентябрь, 628 номерлы карары нигезендә оештырылды.

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт учреждениесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Дәүләт юл хезмәтенең хокуклы варисы булып тора, Казан ш. хакимияте тарафыннан 1997 елның 11 декабрендә теркәлгән, теркәлү номеры: 01-2233.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Дәүләт юл хезмәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Дәүләт юл хезмәте турында» 2002 ел, 29 март, 159 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт учреждениесенә кушу формасында үзгәртеп корылды.

1.2. Идарәне гамәлгә куючы булып Татарстан Республикасы тора.

Идарә мөлкәтенең милекчесе булып Татарстан Республикасы тора.

1.3. Идарәне Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.

1.4. Идарә мөлкәтенең милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

1.5. Идарәнең рәсми атамасы:

тулы атамасы: «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;

кыскартылган атамасы: «Главтатдортранс» ДКУ.

1.6. Идарә коммерциясез оешма булып тора.

Оешу-хокукый формасы – учреждение;

Учреждение тибы – дәүләт казна учреждениесе.

1.7. Идарә юридик зат булып тора, оператив идарә итү хокукында аерым мөлкәте, мөстәкыйль балансы, законнар нигезендә ачтырылган шәхси счетлары, Татарстан

Республикасының дәүләт гербы сурәтләнгән мөһере, гади түгәрәк мөһере, почмаклы штампы, бланклары һәм законнарда каралган башка реквизитлары бар.

1.8. Идарәнең урнашкан урыны (юридик адресы): 420012, Татарстан Республикасы, Казан ш., Достоевский урамы, 18/75.

1.9. Идарә дәүләт теркәвенә алыну вакытыннан башлап юридик зат булып тора һәм үз исеменнән мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокуклар сатып алырга, җаваплылыклар алырга, шикаять белдерүче һәм җаваплы як сыйфатында судларда катнашырга хокуклы.

1.10. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, Министрлык күрсәтмәләренә һәм боерыкларына, бүтән норматив хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.11. Идарә оператив идарә итү хокукында үзенә беркетелгән мөлкәткә карата законнарда билгеләнгән чикләрдә, Министрлык һәм Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган йөкләмәләре, мөлкәтнең билгеләнеше нигезендә ия булу һәм файдалану хокукларын гамәлгә ашыра.

Идарә мөлкәтнең милекчесе ризалыгыннан башка мөлкәтне читләштерергә яки аның белән бүтән ысул белән эш итәргә хокуклы түгел.

1.12. Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган файдаланылмый торган яисә билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне тартып алырга һәм аның белән үз ихтыяры буенча эш итәргә хокуклы.

1.13. Үзенең йөкләмәләре буенча Идарә үз карамагында булган акчалар белән Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

Акчалар җитәрлек булмаганда, Идарә йөкләмәләре буенча Министрлык исеменнән Татарстан Республикасы субсидиар җаваплы була.

Идарә Министрлык йөкләмәләре буенча җаваплы булмый.

## 2. Идарәнең предметы, максатлары, бурычлары һәм функцияләре

2.1. Идарә эшчәнлегенең предметы булып юл-транспорт комплексы объектларын проектлау, төзү, үзгәртеп кору, төзәтү, капиталь төзекләндерү һәм карап тоту өлкәсендәге дәүләт функцияләрен гамәлгә ашырудан, дәүләт заказчысының, заказчы-төзүче оешманың барлык дәрәҗә бюджетлардан дәүләт капитал кертемнәре хисабына финанслана торган функцияләрен башкарудан гыйбарәт.

Юл-транспорт комплексы граждани авиацияне, эчке су, автомобиль, шәһәр электр (метрополитенны да кертеп), сәнәгый, тимер юлны, торба үткәрү транспортын һәм юл хуҗалыгын үз эченә ала.

2.2. Идарә эшчәнлегенең максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1) юл-транспорт комплексы объектларын үстерүне тәэмин итү;

2) автомобиль юлларында һәм ясалма юл корылмаларында хәрәкәт өзеклекләрен һәм чикләүләрне, сезонлы деформацияләрне һәм җимерелүләрне бетерү, стихияле бәла-казаларның нәтиҗәләрен юкка чыгару буенча кирәкле чараларны күрү;

3) Татарстан Республикасының уртак файдаланудагы автомобиль юллары буйлап транспорт чараларының куркынычсыз һәм өзлексез хәрәкәт итүе өчен шартлар тудыру, аларның үткәрүчәнлек сәләтен арттыру.

2.3. Идарә эшчәнлегенең төп төре булып «Транспорт һәм юл хуҗалыгы», «Торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр төзелеше» тора.

Төп эшчәнлек төрләре нигезендә Идарә законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәге дәүләт эшләрен башкара:

дәүләт мөлкәтендә торучы мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү), шул исәптән:

объектларны һәм корылмаларны проектлау, капиталь һәм агымдагы төзәтү, үзгәртеп кору һәм төзү;

объектларны һәм корылмаларны төзегәндә заказчы, төзүче оешма функцияләрен үтәү эшләре;

объектларга һәм биналарга эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтелүен, шулай ук күрсәтелгән объектларны һәм биналарны, җиһазларны һәм чиктәш территорияләрне тиешле торышта карап тотуны тәэмин итү;

автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә эшләр башкару;

инженерлык челтәрләрен, торак, сәнәгый, коммуналь һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны һәм бүтән объектларны проектлау, төзү, үзгәртеп кору, техник яктан үзгәртеп коралландыру һәм капиталь төзекләндерү буенча товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алуны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренең, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең дәүләт (муниципаль) заказчылары өчен тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүгә вәкаләтле орган функцияләрен гамәлгә ашыру.

2.4. Эшчәнлегенең Идарәне оештыру максатларына ирешүдән гыйбарәт булган предметы һәм максатлары нигезендә, ул түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) уртак файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен үстерү буенча дәвамлы программаларны эшләүдә катнаша, эшләрнең агымдагы күләмнәрен һәм юл-транспорт комплексы объектларын төзүгә, үзгәртеп коруга, төәзтүгә, капиталь төзекләндерүгә, карап тотуга һәм техник тәэмин итүгә бюджеттан финанс ихтыяҗын планлаштыра;

2) юл-транспорт комплексы объектларын проектлаганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда, төзәткәндә, капиталь төзекләндергәндә, карап тотканда, юл эшләрен планлаштырганда һәм инвестицияләрне бүлгәндә федераль һәм республика законнары нигезендә юл хуҗалыгы өлкәсендәге төбәк законнарын формалаштырганда катнаша;

3) Татарстан Республикасының уртак файдаланудагы автомобиль юлларына һәм аларның тиешенчә функцияләвен тәэмин итү өчен кирәкле, үзенең оператив идарәлегендә торучы юл хуҗалыгы мөлкәтенә идарә итүне гамәлгә ашыра;

4) юл-транспорт комплексы объектларын проектлау, төзү, үзгәртеп кору, төзәтү, капиталь төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү өлкәсендә эшләр оештыра;

5) проект-смета документациясен эшләүгә биремнәр раслый, документациягә экспертиза уздырылуын һәм аны раслауны оештыра;

6) билгеләнгән тәртиптә проект документациясенә дәүләт экспертизасы уздырылуын тәэмин итә;

7) билгеләнгән тәртиптә проект документациясен һәм юл-транспорт комплексы объектларын төзүгә, үзгәртеп коруга, төзәтүгә һәм капиталь төзекләндерүгә титул исемлекләрен раслый;

8) юл-транспорт комплексы объектларын төзү һәм үзгәртеп кору өчен җирләрне чигерүне һәм сатып алуны килештерә;

9) башкарыла торган эшләрнең һәм кулланыла торган юл-төзелеш материалларының һәм конструкцияләренең сыйфатына лаборатор контроль уздыра;

10) башкаручылар белән дәүләт контрактлары һәм бүтән граждани-хокукый шартнамәләр төзи:

- проект-эзләнү эшләренә, юл-транспорт комплексы объектларын төзү, үзгәртеп кору, төзәтү, капиталь төзекләндерү һәм карап тоту буенча подряд эшләренә;

- җиһаз китертүгә, шәһәр төзү документациясен эшләүгә;

11) дәүләт заказчылары һәм Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләре өчен юл хуҗалыгы объектларында эшләр башкару буенча тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгели, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасындагы килешүләрдә каралган очракларда, муниципаль заказчылар һәм муниципаль бюджет учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр өчен тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) билгеләүгә тиешле муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле учреждениеләре вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

12) законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт контрактлары (шартнамәләре) буенча башкаручылар тарафыннан башкарылган эшләрне кабул итә;

13) башкарыла торган эшләрнең барышына һәм сыйфатына, аларның башкару һәм төзелеше тәмамланган объектларны эксплуатациягә кертү срокларының үтәлешенә төзелеш контролен гамәлгә ашыра, алга таба аларны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт мөлкәтенә яки муниципаль мөлкәткә тапшырып;

14) юл-транспорт комплексы объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, төзәткәндә, капиталь төзекләндергәндә һәм карап тотканда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирә;

15) юл законнары үтәлүен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра һәм аны камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерли;

16) дәүләт ихтыяҗлары һәм Идарә ихтыяҗлары өчен бюджеттан финанслауның расланган программалары чикләрендә товарлар китертүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру юлы белән сатулар оештыра һәм уздыра;

17) автомобиль юлларының торышын яхшырту турында дәүләт идарәсе органнарына мәгълүмат һәм тәкъдимнәр әзерли;

18) Татарстан Республикасы юл тармагының бердәм техник сәясәтен уздыруны гамәлгә ашыра, яңа технологияләр, конструкцияләр һәм материаллар, автомобиль юлларын карап тотуга автомат идарә системаларын, яңа контроль методларын һәм лаборатор җиһазлар кертүне тәэмин итә;

19) базар конъюктурасын өйрәнә, юл эшләре базарын формалаштыруга булышлык күрсәтә;

20) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнары, Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автоюл күзәтчелеге идарәсе, тимер юлы һәм юл оешмалары, инженерлык коммуникацияләре хуҗалары белән юл-транспорт комплексы объектларын куркынычсыз эксплуатацияләү һәм дәүләт юл транспорт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә;

21) фәнни-тикшеренү һәм гамәлгә кертү эшләре, җитештерүне үстерүнең, юл төзелешендә яңа технологияләр һәм материаллар кертүнең максатчан программалары буенча заказчы функцияләрен башкара;

22) инвестиция проектларына аларны тормышка ашыруның барлык стадияләрендә анализ үткәрә;

23) гамәлдәге законнар нигезендә төзелеше тәмамланган объектлар буенча дәүләт кабул итү комиссиясен формалаштыруда һәм аның эшендә катнаша;

24) көзге-кышкы, язгы-җәйге чорларда Татарстан Республикасының уртак файдаланудагы автомобиль юлларының транспорт-эксплуатация торышына өзлексез контроль оештыра һәм транспорт чараларының тәүлек әйләнәсе өзлексез хәрәкәт итүен тәэмин итә;

25) Идарәгә беркетелгән мөлкәтнең саклануын тәэмин итү буенча чаралар күрә;

26) автомобиль юлларыннан файдаланучыларның мәнфәгатьләрен һәм аларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

27) Татарстан Республикасының уртак файдаланудагы автомобиль юлларында хәрәкәт итү шартлары турында хәрәкәттә катнашучыларга һәм мәнфәгатьле оешмаларга вакытында мәгълүмат җиткерә;

28) Татарстан Республикасының уртак файдаланудагы автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыра;

29) Татарстан Республикасының уртак файдаланудагы автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын техник исәпкә алуны һәм паспортлаштыруны, хәрәкәтне исәпкә алуны, автомобиль юлларының һәм күперләрнең торышы турында автоматлаштырылган белешмәләр банкын булдыруны һәм үстерүне гамәлгә ашыра;

30) гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә үз компетенциясенә карый торган мәсьәләләрдә гражданнарга телдән һәм язмача формаларда хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

31) федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризаларны, шикаятьләрне, үтенеч язуларын һәм хокукый холыклы башка документларны төзү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданин мәнфәгатьләрен күрсәтә.

2.5. Идарә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, санитар-гигиеник нормаларны һәм таләпләрне үти, куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итә һәм билгеләнгән таләпләрне бозган өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.

## 3. Министрлык вәкаләтләре

3.1. Министрлык, Идарәнең хокукый статусын регламентлый торган гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, билгеләнгән тәртиптә:

1) аны оештырганда, үзгәртеп корганда, тибын үзгәрткәндә һәм бетергәндә Идарәне Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара;

2) Идарәнең уставын, шулай ук аңа кертелә торган үзгәрешләрне Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган белән килештереп раслый;

3) Идарә уставында каралган төп эшчәнлек төрләренә туры китереп, юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен (алга таба – дәүләт йөкләмәсе) формалаштыра һәм раслый;

4) Идарә эшчәнлеген финанс тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

5) Идарә эшчәнлеге нәтиҗәләре турында һәм аңа беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән файдалану турында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә хисап төзү һәм раслау тәртибен билгели;

6) Идарәнең бюджет сметасын раслый, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы

билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә аны төзү һәм алып бару тәртибен билгели;

7) Идарәнең күчмә мөлкәте белән эш итүне килештерә;

8) Россия Федерациясе законнары нигезендә Идарә эшчәнлегенә контроль башкара;

9) билгеләнгән тәртиптә, казна учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән, автоном учреждение яки бюджет учреждениесе оештыру турында тәкъдим кертә;

10) Гамәлгә куючының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән бүтән функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

## 4. Идарә эшчәнлеген оештыру

4.1. Идарә үзенең структурасында Казан ш. урнашкан идарә аппаратына ия.

4.2. Идарә хуҗалык эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә башка юридик затлар һәм гражданнар белән үзенең мөнәсәбәтләрен шартнамәләр нигезендә төзи.

4.3. Устав максатларын үтәү өчен Идарә мөстәкыйль рәвештә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үз функцияләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен шартнамә нигезләрендә милекчелек формаларына бәйсез рәвештә башка оешмаларны җәлеп итәргә;

2) Министрлык ризалыгы белән һәм законнар нигезендә аерымланган структур бүлекчәләр (филиаллар, вәкиллекләр һ.б.) оештырырга, аларны бетерү һәм үзгәртеп кору турында, тиешле үзгәрешләрне әлеге уставка кертеп, карарлар кабул итәргә, алар турында нигезләмәләр расларга, мондый аерымланган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләрен вазыйфага билгеләргә һәм аннан азат итәргә;

3) мөлкәтнең милекчесе ризалыгы белән, дәүләт мөлкәтен оператив идарә итү хокукында беркетү турында актта билгеләнгән тәртиптә Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган мөлкәте белән эш итәргә;

4) үз компетенциясе чикләрендә һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт идарәсе органнарыннан, предприятиеләрдән һәм төрле милекчелек формасындагы оешмалардан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны соратырга һәм алырга;

5) судларга, прокуратура органнарына, бүтән органнарга мөрәҗәгать итәргә, судта дәгъва белдерүче һәм җавап бирүче булырга;

6) хезмәткә түләү формаларын һәм системаларын, шулай ук, гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, булган чаралар чикләрендә бүләкләүнең башка формаларын ачыкларга һәм билгеләргә;

7) Министрлык белән килештереп штат расписаниесе расларга;

8) уртак файдаланудагы автомобиль юлларын һәм бүтән юлларны төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә подряд оешмаларына гамәлдәге законнарда билгеләнгән нормативларны саклау турында үтәү өчен мәҗбүри күрсәтмәләрне бирергә;

9) гамәлдәге законнарга каршы килми торган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

4.4. Идарә:

1) шартнамә йөкләмәләрен бозган өчен, алардан файдаланганда халыкның сәламәтлегенә зыян килергә мөмкин булган продукциянең, эшләрнең, хезмәтләрнең сыйфаты өчен, ягъни гамәлдәге законнарда билгеләнгән бүтән кагыйдәләрне бозган өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була;

2) шәхси состав буенча документларны исәпкә алуны һәм саклауны, шулай ук Идарә үзгәртеп корылганда һәм бетерелгәндә билгеләнгән тәртиптә аларны үз вакытында дәүләт саклавына тапшыруны тәэмин итә;

3) оператив идарә итү хокукында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы дәүләт мөлкәтен беркетү турында боерык нигезендә дәүләт

мөлкәте реестрын алып бару өчен кирәкле, мөлкәттән файдалану турындагы мәгълүматны милекчегә тапшыра;

4) Министрлыкка Идарә эшчәнлегенең һәр еллык планы проектын һәм фараз күрсәткечләрен, шулай ук аларны үтәү турында хисап тапшыра.

## 5. Идарәнең мөлкәте һәм финанс тәэминаты

5.1. Идарә расланган бюджет системасы буенча финанслана.

5.2. Идарәнең акчалата һәм бүтән формалардагы мөлкәтен формалаштыру чыганаклары булып түбәндәгеләр тора:

1) бюджет акчалары;

2) милекче яки аның тарафтан вәкаләт бирелгән орган тарафыннан тапшырылган мөлкәт;

3) гамәлдәге законнарда тыелмаган бүтән чыганаклар.

5.3. Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен тоту җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чигендә Идарә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.4. Идарәнең мөлкәте төп һәм әйләнеш акчаларыннан, шулай ук бәясе һәм исемлеге мөстәкыйль баланста чагылдырыла торган бүтән кыйммәтләрдән, җиһазлар һәм материаллардан тора.

5.5. Идарәгә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт Татарстан Республикасы мөлкәте булып тора.

5.6. Министрлык тарафыннан Идарәгә беркетү турында карар кабул ителгән мөлкәт белән оператив идарә итү хокукы Идарәдә Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле органнан мөлкәтне акт нигезендә тапшыру вакытыннан башлап барлыкка килә.

5.7. Шартнамә буенча яки бүтән шартларда Идарә тарафыннан сатып алынган мөлкәт гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Идарәнең оператив идарәсенә күчә.

5.8. Мөлкәт белән оператив идарә итү хокукы гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында каралган нигезләрдә һәм тәртиптә, шулай ук Министрлык яки Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган карары буенча мөлкәтне Идарәдән хокуклы нигездә тартып алган очракларда туктатыла.

5.9. Милекчелек хокукы башка затка күчкәндә, Идарә үзендә булган мөлкәт белән оператив идарә итү хокукын саклый.

5.10. Идарә, бюджет акчаларын алучы буларак, түбәндәгеләрне бурычлы:

1) бюджет заявкаларын һәм бюджет акчаларын алу хокукын раслаучы бүтән документларны үз вакытында тапшырырга;

2) максатчан билгеләнешләре нигезендә бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдаланырга;

3) бюджет акчаларыннан файдалану турында хисапны һәм бүтән мәгълүматларны үз вакытында тапшырырга.

5.11. Идарә, бюджет акчаларын алучы буларак, түбәндәгеләргә хокуклы:

1) бюджет исемлегендә расланган күләмгә ярашлы рәвештә бюджет акчаларын үз вакытында алуга һәм куллануга;

2) бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрләмәләрне үз вакытында җиткерүгә.

5.12. Идарә бюджет исәбен алып бара һәм казна учреждениеләре өчен билгеләнгән тәртиптә бюджет хисаплылыгын тапшыра.

Идарә тарафыннан бюджет йөкләмәләрен кабул итү һәм (яки) аларны агымдагы финанс елында һәм план чорында үтәү җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм (яки) бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5.13. Идарә кредитлар (займнар) бирергә һәм алырга, кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга хокуклы түгел.

5.14. Идарә үзенең йөкләмәләре буенча үз карамагында булган акчалар белән җавап бирә.

5.15. Министрлык Идарәгә карата түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) бюджет йөкләмәләре лимитларын җиткерүне;

2) законнарда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен.

5.16. Идарә билгеләнгән тәртиптә мөлкәтне Татарстан Республикасы мөлкәтенең дәүләт реестрында исәпкә алу өчен үз вакытында тапшырырга тиеш.

5.17. Идарәнең казначылык органнарында ачтырылган счетлары (алучының шәхси счеты) була.

5.18. Идарә Идарәне карап тоту һәм аңа йөкләнгән функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен күздә тотылган бюджет акчаларын алучы функцияләрен гамәлгә ашыра.

5.19. Идарә билгеләнгән срокларда Идарә эшчәнлеге турында статистик хисаплылык формаларын әзерли һәм дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, шул исәптән Министрлыкка, тапшыра.

Идарә тарафыннан бюджет акчалары хисабыннан үтәлергә тиешле дәүләт контрактлары, бүтән шартнамәләрне төзү һәм түләү аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм кабул ителгән һәм үтәлмәгән йөкләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашырыла.

## 6. Идарә эшчәнлеген оештыру һәм идарә итү

6.1. Идарәнең җитәкчесе булып директор тора. Директор үзенең вазыйфасына Министрлык тарафыннан билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә. Министрлык директор белән хезмәт шартнамәсе төзи һәм тарката. Идарә директорының вәкаләтләр срогы хезмәт шартнамәсендә билгеләнә.

6.2. Идарә директорының урынбасарлары була. Идарә директорының урынбасарлары вазыйфага Идарә директоры тарафыннан Министрлык белән килештереп билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

6.3. Директор Министрлык каршында хисап тота, үз эшчәнлеген гамәлдәге законнар, әлеге Устав, Министрлык күрсәтмәләре һәм боерыклары нигезендә гамәлгә ашыра.

6.4. Директор компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар аның тарафыннан бер кулдагы идарә нигезендә кабул ителә.

6.5. Директор Идарәнең агымдагы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм түбәндәге хокукларга һәм бурычларга ия:

1) ышанычнамәдән башка Идарә исеменнән эш йөртә, Россия Федерациясенең барлык оешмаларында һәм чит илләрдә аның мәнфәгатьләрен яклый;

2) гамәлдәге законнарда, әлеге Уставта һәм үзе белән төзелгән хезмәт шартнамәсендә билгеләнгән чикләрдә Идарә мөлкәтенә идарә итә;

3) үз вәкаләтләре чикләрендә, шул исәптән башка бирәүгә ышанып тапшыру хокукы белән шартнамә нигезендә, Идарә исеменнән вәкиллек хокукына ышанычнамә бирә;

4) хезмәткәрләрне командировкага җибәрү турында карарлар кабул итә;

5) Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларга карата бүләкләү чараларын күрә һәм аларга түләттерүләр сала;

6) Россиядә һәм чит илләрдә Идарә исеменнән шартнамәләр төзи;

7) гамәлдәге законнар һәм әлеге Устав нигезендә Идарә компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча Идарәнең барлык хезмәткәрләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле боерыклар, күрсәтмәләр, аңлатмалар чыгара;

8) Идарә директоры урынбасарлары арасындагы вазыйфаларны бүлә, Идарәнең барлык хезмәткәрләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирә;

9) билгеләнгән хезмәткәрләр исәбе һәм хезмәткә түләү фонды чикләрендә Идарәнең структурасын, штат расписаниесен раслый;

10) билгеләнгән тәртиптә Идарә акчалары белән эш итү хокукыннан файдалана.

6.6. Директор дәүләт серен һәм коммерция серен саклауны һәм аларның тиешенчә саклануын тәэмин итү буенча чараларны эшли һәм гамәлгә ашыра.

6.7. Директор түбәндәгеләргә сәбәпче булган гаепле гамәлләр өчен персональ җаваплы була:

1) бюджет акчаларыннан максатчан файдаланмау, үзенә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырып, бюджет йөкләмәләре кабул итү;

2) Идарә мөлкәтеннән максатчан файдаланмау;

3) Идарәнең граждани хокукы чикләрендә алыш-бирешләр төзү һәм башкару.

## 7. Хисаплылык һәм контроль

7.1. Идарә эшчәнлек нәтиҗәләренең оператив һәм бухгалтерлык исәбен гамәлгә ашыра, статистик һәм бухгалтерлык хисаплылыгын алып бара, эшчәнлек нәтиҗәләре турында гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда хисап тота, тиешле органнарга гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә финанс һәм статистика хисаплылыгын тапшыра.

7.2. Министрлык, зарурлык булу дәрәҗәсенә карап, Идарә эшчәнлегенә тикшерүләр уздыра, аларның нәтиҗәләрен Идарәгә җиткерә һәм тиешле чаралар күрә.

7.3. Идарә эшчәнлегенә контроль һәм ревизия Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, салым, табигать саклау органнары һәм гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт казна учреждениеләре эшчәнлеген тикшерү йөкләнгән башка органнар тарафыннан үзләренең компетенцияләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7.4. Идарәгә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәттән файдалануга контроль Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 8. Хезмәт мөнәсәбәтләре

8.1. Хезмәткәрләр белән Идарә арасында хезмәт шартнамәсе (контракты) нигезендә барлыкка килгән мөнәсәбәтләр хезмәт турында Россия Федерациясе законнары белән җайга салына.

8.2. Идарә хезмәткәрләргә гамәлдәге законнарда гарантияләнгән хезмәт шартларын һәм хезмәткә түләүнең минималь күләмен, хезмәткәрләрне социаль яклау чараларын тәэмин итә.

8.3. Хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү формасы, системасы һәм күләме Идарә тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлдәге законнар, расланган бюджет сметасы нигезендә исәп лимиты һәм карап тоту нормативлары чикләрендә билгеләнә.

## 9. Социаль эшчәнлек

9.1. Идарә хезмәт шартларын яхшырту буенча чаралар уздыра, гамәлдәге законнар нигезендә хезмәткәрләргә мәҗбүри социаль һәм медицина иминиятләштерүен тәэмин итә.

9.2. Идарә үзенең хезмәткәрләре өчен куркынычсыз хезмәт шартлары тудырырга тиеш һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә аларның сәламәтлегенә китерелгән зыян өчен материаль җаваплы була.

## 10. Мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү һәм җайга салу

10.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы дигәндә Идарә хезмәткәренең шәхси кызыксынучанлыгы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясый алырлык һәм Идарә хезмәткәренең шәхси кызыксынучанлыгы аркасында хезмәткәр эшли торган Идарәнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Идарәнең мөлкәтенә һәм (яки) эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле каршылык килеп чыга яки килеп чыгарга мөмкин булган вәзгыять аңлашыла.

10.2. Идарә хезмәткәренең аның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясый торган яки йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы дигәндә Идарә хезмәткәренең хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә үзе өчен яки өченче затлар өчен акчалар, кыйммәтләр рәвешендә керемнәр, бүтән мөлкәт, шул исәптән мөлкәти холыклар, яки мөлкәти холыклы хезмәтләр алу мөмкинлеге аңлашыла.

10.3. Идарә директоры вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында Министрлыкка хәбәр итәргә бурычлы.

10.4. Идарә хезмәткәре Идарә директорына вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итәргә тиеш. Идарә директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрләмәләрдә булган белешмәләр исемлеге, әлеге белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрләмәләрне теркәү тәртибе Идарә директоры тарафыннан билгеләнә.

## 11. Идарәне бетерү һәм үзгәртеп кору

11.1. Идарәне бетерү яки үзгәртеп кору турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

11.2. Идарәне бетерү ликвидация комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның составы Министрлык тарафыннан раслана.

11.3. Идарәне бетерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Граждан кодексы һәм Идарәне бетерү турында хокукый акт нигезендә Министрлык тарафыннан билгеләнә.

11.4. Тиешле язуны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына керткән вакыттан башлап Идарәне бетерү тәмамланган булып санала, ә Идарә үзенең гамәлдә булуын туктата.

11.5. Идарәнең кредиторларның таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган күчемсез һәм күчмә мөлкәте, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә бетерелә торган Идарә йөкләмәләре буенча түләттерүгә юнәлдерелә алмый торган күчемсез һәм күчмә мөлкәте ликвидация комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт

мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырыла.

11.6. Идарә шәхси состав буенча документларны исәпкә алуны һәм саклауны, шулай ук Учреждение үзгәртеп корылганда яки бетерелгәндә аларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт архивына тапшыруны тәэмин итәргә бурычлы.